**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 май № 359

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категория-ләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче, 2015 ел, 12 март, 146 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның өченче абзацында «махсуслашкан оешма тарафыннан профинансланган» сүзләрен «Татарстан Республикасында капиталь төзелеш объектларын төзүнең дәүләт заказчысы функцияләрен гамәлгә ашыручы махсуслашкан оешма яисә учреждение тәэмин иткән,» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның икенче абзацында «махсуслашкан оешма» сүзләреннән соң «яисә Татарстан Республикасында капиталь төзелеш объектларын төзүнең дәүләт заказчысы функцияләрен гамәлгә ашыручы учреждение» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков